# «Аулак өй»

1И сыйныфы укучылары һәм тәрбиячеләре Шәмсетдинова Ясминә Тәлгать кызы «Аулак өй» күренешен башкардылар. Шул чордагы кебек киенеп Ясминә Тәлгәтовна һәм балалары бик матур итеп чабата биюе башкардылар. Күмәк уеннарны, «тәңкә салыш» уеннарын да уйнап киттеләр. Балалар бик тә тырышып әзерләнгәннәр иде. «Аулак өй»нең нәрсә икәнен мөгаен һәр кеше дә беләдер, чөнки бу гореф гадәт бик борынгыдан килә. Әлек, олылар туганнарына яисә эшләре буенча киткәч, кызлар үзләре генә калганнар һәм кунакка дус кызларын чакырганнар. Озакламый аларга егетләр дә килеп кушылган. Зур һәм шаян төркемдә бию һәм җыр, мәзәкләр сөйләү башланган. Егетләр һәм кызлар милли татар уеннары уйнаганнар. Нәкъ менә шул «Аулак өй» татарларның гореф гадәте булып киткән.

